БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«30» 04 2025 ел

**КАРАР**

№ 147

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында хәрби вакытта эвакуация чараларын оештыру турында

1998 елның 12 февралендәге «Гражданнар оборонасы турында» 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз урыннарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 ДСП номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 05 мартындагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан урыннарда халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне мөмкин булган куркыныч зоналардан эвакуацияләүне планлаштыручы муниципаль берәмлекләргә беркетелгән Татарстан Республикасының имин районнары исемлеген раслау турында» 01-208 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

1.1. Эвакуацияләнә торган халыкны таратып урнаштыру өчен каралган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынын торак пунктлары исемлеген (1нче кушымта);

1.2. Эвакуация пунктының кабул итү бүлмәсе составы турында нигезләмәне һәм аның составын (2нче һәм 3 нче кушымталар);

1.3. Эвакуация пунктының кабул итү бүлмәсе хезмәткәрләренең функциональ бурычлары (4 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә (алга таба - Балтач муниципаль районы) эвакуацияләнә торган халыкны кабул итүне, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне урнаштыруны, беренче чиратта яшәүне тәэмин итүне оештыру максатларында түбәндәге эвакуация органнарын төзергә:

- кабул итү эвакуация пунктлары (алга таба - ПЭП) (5 нче кушымта);

- эвакуацияләнә торган халыкны төшерү пунктлары (алга таба - ПВ) (6 нчы кушымта);

2.1. Кабул итү эвакуация пункты турында Нигезләмә (7 нче кушымта).

2.2. Эвакуацияләнә торган халыкны төшерү пункты турында Нигезләмә (8 нче кушымта).

2.3. Татарстан Республикасының имин районнары территорияләрендә

таралучы һәм эвакуацияләнүче халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне кабул итүне, урнаштыруны һәм беренче чиратта яшәүне тәэмин итүне оештыру турында нигезләмә (9 нчы кушымта).

3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән, төзелә торган эвакуация органнары башлыклары итеп, алар базасында эвакуация органнары төзелә торган оешма һәм учреждение җитәкчеләрен билгеләргә.

4. Карар рәсми басылып чыкканнан соң бер ай эчендә эвакуация органнары (ПЭП, ПВ) башлыкларына төзелә торган эвакуация органнарының шәхси составын билгеләргә, оештыру - планлаштыру документларын эшләргә һәм аларны урнаштыру өчен биналар белән тәэмин итәргә.

5. Эвакуацияләнүче халыкны кабул итүне һәм алар буйсынуындагы территорияләрдә урнаштыруны гамәлгә ашыручы Балтач муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә төзелә торган эвакуация органнары (ПЭП, ПВ) администрацияләренә эшне оештыруда һәм аларны җиһазлауда һәрьяклап ярдәм итәргә тәкъдим итәргә.

6. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» башлыгына кирәкле әйберләр белән тәэмин итү һәм ана белән бала бүлмәсен оештыру өчен ПЭПка якын урнашкан мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен беркетергә.

7. Балтач муниципаль районы Башлыгының 2021 елның 11 сентябрендәге 285 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

8. Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 11 сентябрендәге «Сугыш вакытында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында эвакуация чараларын оештыру турында» 285 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

10.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов